МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.09.2025 г. Казань № 2218

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау Министрлыгының 12.02.2019 № 251-нче номерлы боерыгының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

1995 елның 12 гыйнварыннан 5-ФЗ номерлы «Ветераннар турында» Федераль закон нигезендә, Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендәге сугыш ветераннары өчен госпитальләрдә гражданнарның ташламалы категорияләренә медицина белән тәэмин итүне оештыру максатларында, б о е р а м:

12.02.2019 елның Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау Министрлыгының «Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендәге сугыш ветераннары өчен госпитальләрдә гражданнарның ташламалы категорияләренә медицина ярдәмен оештыру турында», 251-нче номерлы боерыгының 1 нче кушымтасына (Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау Министрлыгының 30.03.2020 елдагы 566-нчы, 28.03.2023 елдагы 590-нчы, 19.06.2024 елдагы 1440-нчы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән бергә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның «Категория исеме» баганасында:

1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1) Хәрби хезмәткәрләр, эчке эшләр органнарының рядовой һәм җитәкчелек составы затлары, милли гвардия гаскәрләре, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясенең мәҗбүри башкарма органнары, прокурорлар, Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләре, шул исәптән запаска (отставкага) чыгучылар, Россия Федерациясе территориясенә коралллы хөҗүм бәреп керүне кире кагу бурычларын үтәгәннәр, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт чигендә һәм махсус хәрби операция уздырыла торган районнарга якын Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә коралллы хөҗүм провокациясе барышында хөҗүмне кире кагу бурычларын үтәгәннәр»;

2.2 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2) Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары карары буенча төзелгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче ирекле формированиеләргә кергән затлар, махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Хәрби Көчләренә (Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренә) йөкләнгән, Россия Федерациясе территориясенә коралды хөҗүмне бәреп керүне кире кагу, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт чигендә һәм махсус хәрби операция уздырыла торган районнарга якын Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә коралды хөҗүм провокациясе барышында хөҗүмне кире кагу бурычларын үтәүче затлар;»;

түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктчаны өстәргә:

«2.5) федераль башкарма хакимият органының коткару хәрби формированиеләре хәрби хезмәткәрләре, махсус хәрби операция барышында эзләү эшләрен үткәрүдә катнашкан гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле зат, 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә шартлау куркынычы булган предметларны зарарсызландыру һәм (яисә) юк итү;»;

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә махсус хәрби операция барышында бурычларны үтәүне тәэмин итү өчен җибәрелгән затлар, 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә бирелгән бурычларны үтәүдә аерым казанышлары булган һәм шул ук вакытта күрсәтелгән территорияләрдә гомумән алганда кимендә алты ай эшләгән, йә нигезле сәбәпләр аркасында вакытыннан алда кайтарылып җибәрелгән затлар»;

3-нче пунктның «Категория атамасы» баганасында:

2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1) Хәрби хезмәткәрләр, эчке эшләр органнарының рядовой һәм җитәкчелек составы затлары, милли гвардия гаскәрләре, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең хәрби хезмәткәрләре, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясенең мәҗбүри башкарма органнары, прокурорлар, Россия Федерациясе территориясенә коралды хөҗүм бәреп керүне кире кагу бурычларын башкарган Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләре, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт чигендә һәм махсус хәрби операция уздырыла торган районнарга якын Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә коралды провокация барышы вакытында бирелгән бурычларны үтәгәндә яралану, контузия, гариплек яки авыру нәтиҗәсендә инвалидлыкка китерелгән затлар;»;

8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары карары буенча төзелгән Россия Федерациясе Хәрби көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче

ирекле формированиеләргә кергән затлар (Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре), махсус хәрби операция барышында, Россия Федерациясе территориясенә коралды хөҗүм бәреп керүне кире кагу, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт чигендә һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә коралды хөҗүм провокация барышында, махсус хәрби операция уздыру районнарына якын булган һәм ирекле формированиедә булу турындагы контракт буенча бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алган яралану, контузия, гариплек яки авыру нәтиҗәсендә инвалидлыкка китерелгән затлар;»;

түбәндәге эчтәлекле 11 пунктчаны өстәргә:

«11) гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле булган федераль башкарма хакимият органының коткару хәрби формированиеләре хәрби хезмәткәрләре, махсус хәрби операция барышында 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә шартлау куркынычы булган предметларны эзләү, зарарсызландыру һәм (яисә) юк итү буенча эшләр үткәрүдә катнашкан вакытта күрсәтелгән эшләрне башкару нәтиҗәсендә алган яралану, контузия, гариплек яки авыру нәтиҗәсендә инвалидлыкка китерелгән затлар.».

Министр вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Р. Абашев